**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

# БОЕРЫК

Казан ш.

10.05.2018 № 239

2017 елның 5 октябрендә 662 номеры белән кабул ителгән
Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

**б о е р а м:**

2017 елның 5 октябрендә 662 номеры белән кабул ителгән Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, яңа редакциядә (тәкъдим ителә) бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының 2017 елның
5 октябрендә кул куелган
662 номерлы боерыгы
(Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының 2018 елның
10 маенда кул куелган
239 номерлы боерыгы
редакциясендә) тарафыннан
расланды

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә спорт разрядларын, спорт хөкемдарларына «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу өчен гаризалар җибәрү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: физик затлар – Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – Гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы урнашу урыны: Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 йорт.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне, дүшәмбе – җомга 9.00 дан алып 18.00га кадәр, төшке аш – 12.30-13.30.

Җәмәгать транспорты белән «Божра»  тукталышына кадәр:

- 1, 91, 35а, 37, 29, 90, 71, 47 нче автобуслар;
- 2, 7, 17, 6, 8, 12 нче троллейбуслар белән.
- «Тукай мәйданы» метро станциясенә кадәр килергә мөмкин.

Территориягә бары тик рөхсәт кәгазе һәм (яисә) шәхесне раслый торган документ белән керергә мөмкин.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аны башкару барышы турында хәбәр җиткерү Министрлыкның Спорт төрләрен үстерү бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан (843) 221-81-19 телефон номеры аша тормышка ашырыла.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасы составына керә торган рәсми сайты (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре) адресы: http://mdms.tatarstan.ru/, электрон почта адресы: mdms@tatar.ru

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматны:

1) Министрлык биналарында гариза бирүчеләр белән эш өчен урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текст мәгълүматлары булган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mdms.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итү вакытында (телефон буенча яки шәхсән);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать итү вакытында (шул исәптән электрон документ рәвешендә дә) алырга мөмкин.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турындагы мәгълүмат Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлык биналарында урнашкан мәгълүмати стендларда урын ала.

Мәгълүмати стендларда дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге документларга туры китереп тормышка ашырыла:

2007 елның 4 декабрендә кул куелган «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, №50, 6242 маддә; 2008, №30 (2 өлеш), 3616 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – 329-ФЗ номерлы федераль закон);

2010 елның 27 июлендә кабул ителгән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

2012 елның 7 маенда кул куелган 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президенты Указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 маддә) (алга таба –Указ);

2008 елның 8 октябрендә кабул ителгән «Физик тәрбия һәм спорт турында» 99-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы («Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы», 2008, 1235 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – 99-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2017 елның 20 февралендә кул куелган 108 нче номерлы боерыгы тарафыннан расланган Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында Нигезләмә (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-

порталы http://www.pravo.gov.ru), 2017, 22 март, теркәлү номеры: 0001201703220019), кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – ББСК);

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2017 елның 28 февралендә кул куелган 134 нче номерлы боерыгы тарафыннан расланган Спорт хөкемдарлары турындагы нигезләмә (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru), 2017, 2 июнь, теркәлү номеры: 0001201706020003), кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә (алга таба – Спорт хөкемдарлары турында Нигезләмә) (алга таба – ТР МК ның 315 нче номерлы карары);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 315 номерлы карары (алга таба – ТР МК 315 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары» җыентыгы журналы, 2005, № 30, 0695 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары» җыентыгы, 2010, № 46, 2144 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) (алга таба – ТР МКның 880 номерлы карары).

1.5. Әлеге Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм атамалар кулланыла:

гариза – 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 1 пункты тарафыннан каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорау;

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелеп, документка кертелгән мәгълүматларның (дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе) мәгълүмат нигезендә документларга кертелгән мәгълүматлар белән туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтә урнашкан эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләр белән документларны кабул итү һәм тапшыру, консультация бирү буенча эш алып бара торган тәрәзә (алга таба – КФҮ читтә урнашкан эш урыны).

ББСК – Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпнең эчтәлеге | Хезмәт яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | «Беренче категорияле спорт хөкемдары» спорт хөкемдарларының спорт разряды, квалификация категориясе бирү, алу, торгызу (алга таба – бирү, алу, торгызу) һәм спорт исеме һәм «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» спорт исемнәрен, квалификация категориясе бирү, алу, торгызу өчен Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим юллау (алга таба – тәкъдим) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү | 329-ФЗ номерлы федераль закон;<br>ББСК;<br>Спорт хөкемдарлары турында нигезләмә |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) | 99-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 315 номерлы Карар |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | 1. Министрлыкның «Беренче категорияле спорт хөкемдары» спорт хөкемдарларының спорт разряды, квалификация категориясен бирү, алу, торгызу турындагы боерыгы күчермәсе (бирүдән, алудан, торгызудан баш тарту турында хат)<br>2. «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» спорт исемнәрен, квалификация категориясе бирү, алу, торгызу өчен Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим юллау (тәкъдимне юллаудан баш тарту турында хат) | 329-ФЗ номерлы федераль закон;<br>ББСК;<br>Спорт хөкемдарлары турында нигезләмә |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнары тарафыннан каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату мөмкинлеге булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату вакыты | Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу документлар пакеты белән гаризаны теркәү моментыннан биш эш көне эчендә башкарыла.<br>Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим итү юллау документлар пакеты белән гаризаны теркәү моментыннан биш эш көне эчендә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктату каралмаган. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар буенча гариза бирүче бирергә тиешле, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен, шул исәптән электрон формада да, кирәк булган документларның тулы исемлеге, аларны бирү тәртибе | 1. Спорт разряды бирү өчен түбәндәге документларны тәкъдим итәргә кирәк:<br>Гариза (3 нче кушымта).<br>Тәкъдим итү (5 нче кушымта), түбәндәгеләрдән тора торган документлар комплекты нигезендә:<br>а) ярышларның баш хөкемдарлары коллегиясе рәисе (баш хөкемдар) тарафыннан кул куелган ярышлар беркетмәсенең күчермәсе яки беркетмәдән өземтә, анда барлык спорт разрядларын бирү өчен нормалар, таләпләрне үтәү һәм аларны үтәү шартлары чагылдырыла;<br>б) СМК, «беренче спорт разряды», «икенче спорт разряды», «өченче спорт разряды» (халыкара ярышлардан тыш) спорт разрядларын бирү өчен – ярышларның баш хөкемдарлары коллегиясенең рәисе һәм ярышларны үткәрә | 329-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>ББСК;<br>Спорт хөкемдарлары турында нигезләмә |

| | | |
|---|---|---|
| | торган оешма тарафыннан вәкаләт бирелгән зат кул куйган ;<br>яшүсмерләргә спорт разряды бирү өчен – хөкемдарлар коллегиясе рәисе (баш хөкемдар) кул куйган хөкемдарлар коллегиясенең составы һәм квалификациясе турындагы белешмә кәгазе күчермәсе;<br>в) 3х4 см размердагы 2 фотография.<br>г) спортчының физкультура-спорт оешмасында, спорт әзерлеген тормышка ашыра торган яисә белем бирә торган оешмада (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе туктатылу очрагында) булуын раслый торган документ күчермәсе;<br>д) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләре күчермәсе, шулай ук кандидатның тору урыны турында мәгълүмат булган битләр күчермәсе, ул булмаган очракта – Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданины паспортының фамилия, исеме, атасының исеме (булган очракта), документны биргән орган, документның гамәлдән чыгу вакыты турында мәгълүмат булган битләре күчермәсе (яшүсмерләр спорт разрядларыннан тыш) н;<br>14 яше тулмаган затлар өчен – туу турындагы таныклык күчермәсе.<br>Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәткәрләр Россия Федерациясе гражданы паспорты урынына хәрби билет күчермәсен бирә ала.<br>2. «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү өчен түбәндәге документларны тәкъдим итәргә кирәк:<br>Гариза (4 нче кушымта).<br>Тәкъдим итү (Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы форма буенча түбәндәгеләрдән торган документлар комплекты нигезендә:<br>а) мөһер (булган очракта) һәм региональ спорт федерациясе, федераль орган бүлекчәсе җитәкчесе яки вазыйфаи затының имзасы белән расланган исәп карточкасы күчермәсе;<br>б) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләре күчермәсе, шулай ук кандидатның тору урыны турында мәгълүмат булган битләр күчермәсе, ул булмаган очракта – Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданины паспортының фамилия, исеме, атасының исеме (булган очракта), документны биргән орган, документның гамәлдән чыгу вакыты турында мәгълүмат булган битләре күчермәсе;<br>в) Кандидатларга квалификация категорияләрен бирү Спорт хөкемдарлары | |

| | | |
|---|---|---|
| | турындагы нигезләмәнең 25, 26 пунктларының өченче пункты буенча тормышка ашырылганда - «Россиянең халыкара класска ия булган спорт мастеры» яисә «Россиянең спорт мастеры» таныклыгы күчермәсе;<br>г) 3х4 см размердагы 2 фотография.<br>Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе гражданы паспортының күрсәтелгән битләре күчермәсе урынына хәрби билет күчермәсен бирә ала.<br>3. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәре бирү өчен тәкъдим юллау өчен түбәндәге документларны әзерләп җибәрергә кирәк:<br>Гариза (1 нче кушымта).<br>Тәкъдим (5 нче кушымта), ул түбәндәге документларны үз эченә алырга тиеш:<br>а) ярышларның баш хөкемдарлары коллегиясе рәисе (баш хөкемдар) тарафыннан кул куелган ярышлар беркетмәсенең күчермәсе яки беркетмәдән өземтә, анда нормаларны, таләпләрне үтәү һәм аларны үтәү шартлары чагылдырыла;<br>б) ярышларның баш хөкемдарлары коллегиясенең рәисе (баш хөкемдары) тарафыннан кул куелган хөкемдарлар коллегиясенең составы һәм квалификациясе турындагы белешмә кәгазе күчермәсе (халыкара | |

| | | |
|---|---|---|
| | ярышлардан тыш);<br>в) «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» таныклыклары күчермәсе;[1]<br>г) 3x4 см размердагы 2 фотография;<br>д) спортчының физкультура-спорт оешмасында, спорт әзерлеген тормышка ашыра торган яисә белем бирә торган оешмада (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе туктатылу очрагында) булуын раслый торган документ күчермәсе;<br>е) Башкарма хакимият органының региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе эшен туктату турында документы күчермәсе (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе туктатылу очрагында);<br>ж) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләре күчермәсе, шулай ук кандидатның тору урыны турында мәгълүмат булган битләр күчермәсе, ул булмаган очракта – Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданины паспортының фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), документны биргән орган, документның гамәлдән чыгу вакыты турында | |

[1] Таныклык күчермәләре хөкемдарлар коллегиясенә кергән һәм спортчы нормалар, таләпләр һәм шартларны башкарган ярышларда хөкем итүне башкарган спорт хөкемдарлары тарафыннан тәкъдим ителгән 3 тән дә ким булмаган санда булырга тиеш.

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат булган битләре күчермәсе.<br>14 яшькә җитмәгән затларга – туу турында таныклык күчермәсе.<br>Хәрби чакырылыш буенча хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе гражданы паспорты урынына хәрби билет күчермәсен бирә ала.<br>4. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү максаты белән тәкъдим юллау өчен түбәндәге документларны әзерләп җибәрергә кирәк:<br>Гариза (2 нче кушымта).<br>Тәкъдим (Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы форма буенча), ул түбәндәгеләрдән тора торган документлар комплекты белән:<br>а) мөһер (булган очракта) һәм региональ спорт федерациясе, федераль орган бүлекчәсе җитәкчесе яки вазыйфаи затының имзасы белән расланган исәп карточкасы күчермәсе;<br>б) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләре күчермәсе, шулай ук кандидатның тору урыны турында мәгълүмат булган битләр күчермәсе, ул булмаган очракта – Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданины паспортының фамилия, исем, атасының исеме (булган | |

| | | |
|---|---|---|
| | очракта), документны биргән орган, документның гамәлдән чыгу вакыты турында мәгълүмат булган битләре күчермәсе;<br>в) Квалификация категорияләрен бирү Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 25, 26 пунктлары буенча тормышка ашырыла торган кандидатлар өчен – «Россиянең халыкара класска ия булган спорт мастеры» яисә «Россиянең спорт мастеры» таныклыгы күчермәсе;<br>г) 3x4 см размердагы 2 фотография.<br>Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе гражданы паспортының күрсәтелгән битләре күчермәләре урынына хәрби билет күчермәсен бирә ала.<br>5. Спорт разрядларын һәм исемнәрен кире алу һәм яңадан торгызу өчен 8 нче кушымта нигезендә язылган Гариза тәкъдим итәргә кирәк. Ул үз эченә түбәндәге мәгълүматны ала:<br>а) аңа карата спорт разрядын, исемен, квалификация категориясен кире алу яки яңадан торгызу турында гариза бирелгән спортчының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне;<br>б) спорт разрядын, исемен, квалификация категориясен биргән дата һәм оешма документының номеры;<br>в) спорт разрядын, исемен, квалификация | |

| | | |
|---|---|---|
| | категориясен кире алу һәм яңадан торгызу өчен нигез барлыгын раслый торган мәгълүмат (кире алу һәм яңадан торгызу өчен җирлек булганны раслый торган документларны беркетеп).<br>6. Спорт хөкемдарларының квалификация категориясен кире алу һәм яңадан торгызу өчен 9 нчы кушымта нигезендә Гариза тәкъдим итәргә кирәк, ул үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:<br>а) квалификация категориясен кире алу яисә яңадан торгызу турында гариза бирелгән спорт хөкемдарының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне;<br>б) квалификация категориясен бирү яисә кире алу турында оешма документының номеры һәм дата;<br>в) квалификация категориясен кире алу яисә яңадан торгызу өчен нигез барлыгын раслый торган мәгълүмат (кире алу һәм яңадан торгызу өчен җирлек булганны раслый торган документларны беркетеп).<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документларны гариза бирүче кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тәкъдим итәргә (юлларга) мөмкин:<br>шәхсән (региональ спорт федерациясе яисә федераль орган бүлекчәсенең вәкаләтле заты тарафыннан);<br>почта аша. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар буенча дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Әлеге категориягә туры килергә мөмкин булган документларны бирү таләп ителми. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актларда каралган очракларда килешү таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган башкарма хакимият органы тормышка ашыра торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структура подразделениеләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү кирәк түгел.<br>. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты булмау (тулы булмавы) гаризаны кабул итүдән баш тартуга сәбәп булып тора. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату яисә аны күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы | 1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк.<br>2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту | 329-ФЗ номерлы федераль закон;<br>ББСК; |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге | өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:<br>2.1. Спорт исемен бирүдә:<br>а) бөтенроссия спорт федерациясенең спорт исемен бирү өчен тәкъдимне килештерүдә нигезләнгән кире кагуы;<br>б) спортчының спорт исеме бирү өчен әзерләнгән документларда күрсәтелгән нәтиҗәләренең Министрлык тарафыннан расланган нормаларга, таләпләргә һәм аларны башкару шартларына туры килмәве;<br>в) спортчы тарафыннан норма, таләп һәм аларны үтәү шартлары башкарылган ярышларга кадәр яисә аларны үткәргән көнне спортчыга карата спорт дисквалификацияләве;<br>г) регионара һәм бөтенроссия рәсми физик тәрбия чаралары һәм спорт ярышлары турындагы нигезләмәләр (регламентлар), аларны оештыручылар тарафыннан билгеләп куелган ярышларга кертү шартларын бозу.<br>2.2. Спорт разрядын бирүдә:<br>а) спортчының спорт разряды бирү өчен әзерләнгән документларда күрсәтелгән нәтиҗәләренең Министрлык тарафыннан расланган нормаларга, таләпләргә һәм аларны башкару шартларына туры килмәве;<br>б) спортчы тарафыннан норма, таләп һәм аларны үтәү шартлары башкарылган ярышларга кадәр яисә аларны үткәргән көнне спортчыга | Спорт хөкемдарлары турында нигезләмә 329-ФЗ номерлы федераль закон;<br>ЕВСК; 2.1. Спорт исемен бирүдә: |

| | | |
|---|---|---|
| | карата спорт дисквалификацияләве үткәрү;<br>в) физик тәрбия чаралары һәм (яисә)спорт ярышлары турындагы нигезләмәләр (регламентлар) тарафыннан билгеләп куелган, аларны оештыручылар раслаган ярышларга кертү шартларын бозу.<br>2.3. . Спорт исеменнән мәхрүм итүдә:<br>а) тәкъдим ителгән мәгълүматларның ББСК Нигезләмәсенең 64 нче пункты тарафыннан каралган спорт исеменнән мәхрүм итү шартларына туры килмәве;<br>б) Башкарма хакимият органы яки гомумроссия спорт федерациясе тарафыннан элегрәк шул ук шартларда бирелгән спорт исеменнән мәхрүм итү турындагы гариза буенча Министрлык карары булу.<br>2.4 Спорт разрядыннан мәхрүм итүдә:<br>а) тәкъдим ителгән мәгълүматларның ББСК Нигезләмәсенең 83 нче пункты тарафыннан каралган спорт разрядыннан мәхрүм итү шартларына туры килмәве;<br>б) спорт федерациясе, физик тәрбия-спорт оешмасы, спорт әзерлеген тормышка ашыра торган оешма, белем бирү оешмасы яки Гариза бирүче тарафыннан элегрәк шул ук шартларда бирелгән спорт разрядыннан мәхрүм итү турындагы гариза буенча оешма карары булу. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 2.5. . Спорт исемен торгызуда:<br>а) тәкъдим ителгән мәгълүматларның ББСК Нигезләмәсенең 73 нче пункты тарафыннан каралган спорт исемен торгызу шартларына туры килмәве;<br>б) Башкарма хакимият органы, гомумроссия спорт федерациясе яки спортчы тарафыннан элегрәк шул ук сәбәпләр буенча бирелгән спорт исемен торгызу турындагы гаризасы буенча Министрлыкның карары булу.<br>2.6. Спорт разрядын торгызуда:<br>а) тәкъдим ителгән мәгълүматларның ББСК Нигезләмәсенең 92 нче пунктының икенче абзацында каралган спорт разрядын торгызу шартларына туры килмәве;<br>б) спорт федерациясе, физик тәрбия-спорт оешмасы, спорт әзерлеген тормышка ашыра торган оешма, белем бирү оешмасы яки Гариза бирүче яки спортчы тарафыннан элегрәк шул ук сәбәпләр буенча бирелгән спорт разрядын торгызу турындагы гариза буенча оешма карары булу.<br>2.7. Министрлык тарафыннан расланган Квалификация таләпләрен үтәмәү (спорт төрләре буенча) квалификация категориясен бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.<br>2.8. Бөтенроссия категориясеннән мәхрүм итүдә:<br>а) тәкъдим ителгән мәгълүматларның | |

| | | |
|---|---|---|
| | Спорт хөкемдарлары турындагы Нигезләмәнең 48 нче пунктында каралган бөтенроссия категориясеннән мәхрүм итү шартларына туры килмәве;<br>б) Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы яки гомумроссия спорт федерациясе тарафыннан элегрәк шул ук шартларда бирелгән бөтенроссия категориясеннән мәхрүм итү турындагы гариза буенча Министрлык карары булу.<br>2.9. Спорт хөкемдарлары турындагы Нигезләмәнең 67 нче пунктында каралган квалификация категориясеннән мәхрүм итү өчен шартның тәкъдим ителгән мәгълүматларга туры килмәве квалификация категориясеннән мәхрүм итүгә нигез булып тора.<br>2.10. Бөтенроссия категориясен яңадан торгызуда:<br>а) тәкъдим ителгән мәгълүматларның Спорт хөкемдарлары турындагы Нигезләмәнең 57 нче пунктында каралган бөтенроссия категориясен торгызу шартларына туры килмәве;<br>б) Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы, гомумроссия спорт федерациясе яки спорт хөкемдары тарафыннан элегрәк шул ук шартларда бирелгән бөтенроссия | |

| | | |
|---|---|---|
| | категориясен торгызу турындагы гаризасы буенча Министрлык карары булу.<br>2.11. «Беренче категория спорт хөкемдары» квалификация категориясен торгызудан баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:<br>а) тәкъдим ителгән мәгълүматларның Спорт хөкемдарлары турындагы Нигезләмәнең 76 нчы пунктында каралган квалификация категориясен торгызу шартларына туры килмәве;<br>б) региональ спорт федерациясе яки спорт хөкемдары тарафыннан элегрәк шул ук шартларда бирелгән квалификация категориясе торгызу турындагы гариза буенча оешма карары булу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүне алу тәртибе, зурлыгы һәм нигезе | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган түләү алу, шул исәптән әлеге түләү зурлыгын исәпләп чыгару методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, тәртибе, зурлыгы һәм нигезе | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүләрне тәкъдим итү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү | Дәүләт хезмәтен алу турында гариза | 601 номерлы Указ |

| | | |
|---|---|---|
| турында гариза биргән чакта һәм әлеге хезмәтне күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | биргәндә һәм шундый төр хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәсен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнелмәгән. | |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада соравын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне үк.<br>Электрон формада ял көне (бәйрәм көннәрендә) кергән мөрәҗәгать ял көненнән (бәйрәм көннәреннән) соң килә торган эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына, шул исәптән күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә уңайлы булуларын тәэмин итүгә, шундый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа рәвешендәге мәгълүматны урнаштыру һәм бизәүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгынны сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәк булган җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм бүлмәләрдә тормышка ашырыла.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына тоткарлыксыз килү (биналарга уңайлы керү-чыгу юллары һәм бина эчендә җайлы йөрү) мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа рәвешендәге мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең уңайлылыгы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта гариза бирүче һәм вазыйфаи | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең уңайлылыгы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итү һәм бирү алып барыла торган биналарның җәмәгать транспорты уңайлы булган зонада урнашуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| затларның үзара тәэсир итешү саны һәм дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында дәүләт хезмәтен алуның мөмкин булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр ярдәмендә мәгълүмат алу мөмкинлеге | 2) белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү алып барыла торган биналарның кирәк кадәр санда булуы;<br>3) мәгълүмат стендларында, мәгълүмат ресурсларында, «Интернет» челтәрендә дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) гаризаны Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурслары ярдәмендә электрон формада бирү мөмкинлеге;<br>5) документларны кабул итү, бирү алып барыла торган биналарның инвалидлар өчен уңайлы булуы;<br>6) башка затлар белән тигез күләмдә хезмәт алуга комачаулый торган башка каршылыкларны узу өчен инвалидларга ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) гаризаларны кабул итү һәм карау вакытын саклау;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3) дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан җибәрелгән Регламентны бозуларга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>4) гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара тәэсир итешү саны:<br>турыдан-туры гариза биргән чакта һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алган чакта – икедән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гаризаны һәм документларны почта аша яки электрон рәвештә юллаган очракта – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән үзара тәэсир итешүнең дәвамлылыгы – 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте электрон рәвештә, күпфункцияле үзәкләр аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ераклаштырылган хезмәт урыннарында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче тарафыннан Министрлыкка мөрәҗәгать иткән чакта – телдән (шәхсән яисә телефон буенча) яисә язмача рәвештә, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.<br>Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны Интернет челтәре ярдәмендә тапшыру тәртибе турында консультация үткәрү мөмкинлеге бар. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтә урнашкан эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән чактагы гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза язучыга консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) спорт разряды яки спорт хөкемдарының «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу турында боерык проектын әзерләү;

4) спорт дәрәҗәсе, «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу өчен Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим белән бергә җибәрелә торган хатны әзерләү;

5) спортчының зачет квалификация кенәгәсенә язу белән бергә спорт разряды бирү (биргән вакытта тиешле категория значогы белән) һәм яңадан торгызу турында боерыкның расланган күчермәсен һәм спорт разрядыннан мәхрүм иткән вакытта боерыкның расланган күчермәсен бирү;

6) спорт хөкемдары кенәгәсенә бирелгән хөкемдарлык категориясен язу белән бергә спорт хөкемдарының «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү (биргән вакытта тиешле категория значогы белән) турында боерыкның һәм квалификацияле хөкемдарлык категориясеннән мәхрүм итү турында боерыкның расланган күчермәсен бирү;

7) техник хатаны төзәтү (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хата).

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 11 нче кушымтада тәкъдим ителде.

3.2. Гариза тапшыручыга консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яисә) почта ярдәмендә (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән гариза формасы һәм (яисә) дәүләт хезмәтен алу өчен кирәк булган башка мәсьәләләр буенча консультацияне тормышка ашыра. Кирәк булган очракта Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнеп куела торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, почта буенча, Интернет челтәре, электрон почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да бирелергә мөмкин.

3.3.2. Министрлыкка гариза биргән чакта Бүлек белгече түбәндәгеләрне тикшерүне тормышка ашыра:

- гаризада билгеләнгән форма буенча мәгълүматның (белешмәләр, нигезләр) булуын, документларның комплектта булуын;

- гаризада бирелгән мәгълүматның доументлар комплектында булган белешмәләр, нигезләргә туры килүен.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге административ регламентның 2.8. пунктында каралган сәбәп булмаган очракта оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге (алга таба – Оештыру бүлеге) белгече түбәндәге гамәлләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза бирүченең кулына яки почта буенча яки электрон почта аша (аның теләге буенча), документларны кабул итү көне, аңа сугылган керү номерен күрсәтеп, гариза күчермәсен җибәрә;

гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар алмашы ведомствоара системасы (алга таба – электрон документлар алмашы) аша электрон формада Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрына (алга таба – министр) җибәрә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен нигезләп гариза бирүченең телдән соравы буенча язмача баш тарту әзерли.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура гариза кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза, яки Гариза бирүчегә гаризаны кабул итүдән баш тарту турында язмача белдерү.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган гариза.

3.3.4. Министрның беренче урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура гариза теркәлгән көнне тормышка

ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган гариза.

3.3.5. . Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны билгели һәм аңа башкарып чыгу өчен гаризаны тапшыра.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза.

3.4. Гаризаны карау һәм аның буенча карар кабул итү

3.4.1. Бүлек белгече:

документларда административ регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булуын карый, ягъни спорт разряды, спорт хөкемдарына квалификация категориясе бирү яки бирүдән баш тарту, разряд, квалификация категориясеннән мәхрүм итү, яңадан торгызу мөмкинлеген карый һәм бирү турында боерык проекты әзерли яки кире кагу сәбәбен күрсәтеп гариза бирүчегә кире кагу турында хат (алга таба – боерык, хат проектлары) әзерли;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим белән бергә җибәрелә торган хат проектын яки спорт исеме яки гариза бирүчегә «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү өчен тәкъдим юллауны кире кагу турында кире кагу сәбәпләрен күрсәткән хат проектын (алга таба – бергә тапшырыла торган хат проекты) әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар гаризаның башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган көненнән алып биш эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерү өчен юлланган боерык проектлары, кире кагу турында хат, бергә тапшырыла торган хат проекты.

3.4.2. Бүлек башлыгы әзерләнгән боерык, хат, бергә тапшырыла торган хат проектларының дөреслеген тикшерә, килештерә һәм аларны килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура боерык, хат проектларының, бергә тапшырыла торган хат проектының килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерү өчен юлланган боерык проектлары, кире кагу турында хат, бергә тапшырыла торган хат проекты.

3.4.3. Министрның беренче урынбасары боерык проектларын, кире кагу турында хатны, бергә тапшырыла торган хат проектын килештерә, Бүлеккә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура боерык проектлары, кире кагу турында хат, бергә тапшырыла торган хат проектының министрның беренче урынбасарына килештерүгә кергән көннән алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән боерык, хат проектлары, бергә тапшырыла торган хат проекты.

3.4.3. Министрның беренче урынбасары боерык проектларын, кире кагу турында хат, бергә тапшырыла торган хат проектын килештерә, Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура боерык проектлары, кире кагу турында хат, бергә тапшырыла торган хат проектының министрның беренче урынбасарына килештерүгә кергән көннән алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән боерык проектлары, хат, бергә тапшырыла торган хат проекты.

3.4.4. Бүлек белгече килештерелгән боерык, кире кагу турындагы хат проектларын, бергә тапшырыла торган хат проектын имза куяр өчен министрга юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура боерык, кире кагу турындагы хат проектларын, бергә тапшырыла торган хат проектын министрның беренче урынбасары килештергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имза куяр өчен министрга юлланган боерык, кире кагу турындагы хат проектлары, бергә тапшырыла торган хат проекты.

3.4.5. Министр дәүләт хезмәтен күрсәтү турында боерык, хат проектларын яки дәүләт хезмәтен күрсәтүне кире кагу турында хат проектын, бергә тапшырыла торган хат проектын имзалый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура боерык, хат проектлары, бергә тапшырыла торган хат проектын имзалау өчен министрга юллаган вакыттан алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган боерык һәм кире кагу турындагы хат, бергә тапшырыла торган хат.

3.5. Бүлек белгече:

зачет квалификация кенәгәсендә спорт разряды бирү турында яки спорт хөкемдары кенәгәсендә спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турында тамга куя;

гариза бирүче беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән очракта бирелгән разрядлы зачет квалификация кенәгәсен яки бирелгән категорияле спорт хөкемдары кенәгәсен тапшыра.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Нәтиҗә: гариза бирүчегә зачет кенәгәсен бирү.

3.6. Техник хатаны төзәтү (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата) (алга таба – техник хата).

Техик хатаны төзәтү турында гаризаны гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелә.

Спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсен яңадан рәсмиләштерү техник хаталарны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата) (алга таба – техник хата) юкка чыгару белән бәйле рәвештә тормышка ашырыла.

Спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары

кенәгәсен яңадан рәсмиләштерү техник хата киткән гариза бирүчегә элек бирелгән спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсе белән бергә тапшырылып, теркәлү узган гариза (тәкъдим ителгән форма әлеге Регламентның 9 нчы Кушымтасында бирелде) нигезендә тормышка ашырыла.

3.6.1 Оештыру эше, эшләр һәм тикшерү бүлеге белгече (алга таба – Оештыру бүлеге):

теркәлгән документлары белән бергә техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм терки;

техник хатаны төзәтү турында гаризаны электрон документлар алмашы ведомствоара бердәм системасы аша министрга юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза кергән көндә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза.

3.6.2. Министр техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына юлланган техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.6.3. Министрның беренче урынбасары техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карап чыгу өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карап чыгу өчен Бүлек башлыгына юлланган техник хатаны төзәтү турында гариза

3.6.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгели һәм башкару өчен аңа техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.6.5. Бүлек белгече:

спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсен яңадан рәсмиләштерә;

гариза бирүчегә спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсен яңадан рәсмиләштерү турында хат проекты әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны башкару өчен Бүлек белгеченә юллаган көннән соң бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерү өчен юлланган спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турында кенәгәсе, гариза бирүчегә хат проекты.

3.6.6. Бүлек башлыгы әзерләнгән спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсенең яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсенең дөреслеген тикшерә, гариза бирүчегә хат проектын килештерә һәм килештерү өчен аны министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсе һәм хат проекты килештерү өчен Бүлек башлыгына килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерү өчен юлланган хат проекты.

3.6.7. Министрның беренче урынбасары спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсе белән бергә кергән гариза бирүчегә аталган хат проектын килештерә һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсе белән бергә кергән килештерелгән хат проекты.

3.6.8. Бүлек белгече килештерелгән хат проектын имзалау өчен министрга юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура хат проектын министрның беренче урынбасары килештергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзалау өчен министрга юлланган хат проекты.

3.6.9. Министр гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат проектын имзалый.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура хат проектының имзалау өчен министрга юлланган көненнән алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә министр тарафыннан имзаланган хат.

3.6.10. Бүлек белгече спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсен министр кул куйган хат белән бергә Оештыру бүлегенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедура хатка министр тарафыннан кул куелган көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: оештыру бүлегенә юлланган гариза бирүчегә хат.

3.6.11. Оештыру бүлеге белгече министр кул куйган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы хатны теркәүне башкара, әлеге хат гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә яки, гаризада андый үтенеч булган очракта, кулга бирелә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура гариза бирүчегә дип аталган хатка министр тарафыннан кул куелган көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган хат.

3.6.12. Бүлек белгече спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсен кулга бирә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнелә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: техник хатасы төзәтелгән спорт разряды бирү турындагы зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турындагы спорт хөкемдары кенәгәсен бирү.

3.7. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә, күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күп функцияле үзәкләренең читтә урнашкан эш урыннарында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм формасы

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан административ регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә карата таләпләрне билгели торган башка төр норматив хокукый актларны саклау һәм үтәүне агымдагы тикшерү Бүлек башлыгы һәм Оештыру бүлеге башлыгы тарафыннан тикшерүләр уздыру юлы белән тормышка ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлылыгын тикшерү тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, карауны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәленә (гамьсезлегенә) карата шикаятьле мөрәҗәгатьләргә җавап язуны үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен тикшерү формалары булып түбәндәге тикшерүләрне үткәрү тора:

эш башкаруны алып баруны;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге административ регламент) таләбенә туры килүен;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен үтәүне;

дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен үтәүне.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планнары нигезендә тормышка ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

4.2. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта гаепле дип танылган дәүләт хезмәте

күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнарның, шулай ук аның вазыйфаи затлары һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва бирү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте алучыларның Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затына, яисә Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр – Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар. Министр кабул иткән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда да:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында Гариза бирүченең гаризасын теркәү вакытын бозган очракта;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын яисә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар бирү тәртибен бозганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп иткәндә;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүне кире каккан чакта;

5) әгәр кире кагу өчен нигезләмәләр федераль законнар, аларга бәйле рәвештә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире какканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп иткән очракта;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык, аның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозган чагында;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яисә тәртибен бозганда;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең

башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатканда.

5.2. Шикаять язма формада кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Министрлыкның, министрлыкның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең, Министрның карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять почта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mdms.tatarstan.ru/) файдаланып, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарту очрагында, яисә андый төзәтүләр өчен билгеләнгән вакытны бозу буенча шикаять биргән очракта – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә дәүләт хезмәткәренең исеме.

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында мәгълүматлар, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүматлар.

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамьсезлеге) белән килешмәү өчен нигез булып торган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче шикаятькә анда сурәтләнгән дәлилләрне раслаучы документларның күчермәләрен бирә ала. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) Шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җибәргән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтү, гариза бирүчегә

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләр карау буенча вәкаләтләре булган вазыйфаи зат тиз арада булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентының
1 нче кушымтасы

(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исеме бирү турында
күрсәтмә җибәрү турында
гариза

спортчы ___________________________________________________
Ф.И.Аи
Кушымта:

_________________________________________________________________;
(ББСК буенча билгеләнгән документлар комплекты)

___________________________________________________________________________
Үтенеч юллый торган оешманың вәкаләтле затының вазыйфы атамасы, имзасы, фамилиясе һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Оешма (региональ спорт оешмасы) бланкында рәсмиләштерелә

Гаризаны теркәү турында билге № ____________________________

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт
министрлыгына
спорт исемнәрен яисә
«Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация
категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу
буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентының
2 нче кушымтасы(тәкъдим ителә
торган форма)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

## Россия Федерациясе Спорт министрлыгына «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү турында күрсәтмә җибәрү турында гариза

Сездән Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт хөкемдары ____________________________
квалификация категориясе

_____________________________________________________
Ф.И.Аи
«Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү турында
күрсәтмә җибәрү мөмкинлеген каравыгызны сорыйбыз.

Кушымта:

____________________
(Хөкемдарлар турында нигезләмә буенча билгеләнгән документлар комплекты)
__________________________________________________________________________
Үтенеч юллаучы оешманың вәкаләтле затының вазыйфасы атамасы, имзасы, фамилиясе һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Үтенеч җибәрүче оешма(региональ спорт оешмасы) бланкында рәсмиләштерелә

Гаризаны теркәү турында билге № ____________________________________

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентының
3 нче кушымтасы
Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

# Спорт разряды бирү турында гариза

______________________________________________________________

(күрсәтмә юллаучы оешманың атамасы)
-____________ булган
(спорт разряды)

______________________________________________________________________________

спортчы ______________________(Ф.И.Аи) спорт төре «_____________________»

Кушымта:
______________________________________________________________________;
(ББСК буенча документларның билгеләнгән комплекты)

____________________________________________________________________
Спортчыга күрсәтмә юллаучы оешманың вәкаләтле затының вазыйфасы атамасы, имзасы, фамилиясе һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Оешма (региональ порт оешмасы) бланкында рәсмиләштерелә.
Гаризаны теркәү турында билге № _______________________________________________________

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентының
4 нче кушымтасы

(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

## «Беренче категорияле спорт хөкемдары»

## квалификация категориясен бирү турында гариза

_________________________________________________
(Ф.И.Аи)
Кушымта:

____________________________________________________________________________________________________
(Хөкемдарлар турында нигезләмә буенча билгеләнгән документлар комплекты)

Үтенеч юллаучы оешманың вәкаләтле затының вазыйфасы атамасы, имзасы, фамилиясе һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Үтенеч җибәрүче оешма (региональ спорт федерациясе) бланкында рәсмиләштерелә.

Гаризаны теркәү турында билге № _____________________________________

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу  һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентының
5 нче кушымтасы

(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

| ПРЕДСТАВЛЕНИЕ | МС (МСМК,ГС) Необходимо выбрать **Бланк зеленого цвета (после выбора, лишнее удалить)** | | | | Фото 2 шт. (3×4 см) **в блоке** |
|---|---|---|---|---|---|
| Вид спорта | | | | | |
| Фамилия | | Имя | | | |
| Отчество | | Дата рождения | число | месяц | год |
| | | | | | |
| Республика, край, область, округ | | Город (село, поселок) | | | |
| ВДФСО, ведомство | | Спортивная школа | ДЮСШ, СДЮШОР, ШВСМ ненужное зачеркнуть | | |
| Образование | | Образование физкультурное | | | |
| Место учебы (работы), должность | | | | | |
| Домашний адрес | | | | | |

| Предыдущее звание | Дата присвоения или Подтверждения | Ф.И.О. тренеров подготовивших спортсмена | Тренерская категория |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| Региональная спортивная федерация | Министерство по делам молодежи и спорту Республики Татарстан |
|---|---|
| М.П.<br>**Руководитель**<br>(подпись) | М.П.<br>Первый заместитель министра<br>Х.Х.Шайхутдинов_______________<br>(подпись) |
| Дата | Дата |

| ОСНОВНЫЕ ПОКАЗАТЕЛИ (нормативы) | | | Дата поступления в Минспорт России |
|---|---|---|---|
| Дата выполнен. ч-ло, м-ц, год | Наименование соревнований (дисциплины, вес) | Ранг, категория соревнов. | Показ. Результат (должность судьи) |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | ЕКП № | | |
| | | | |
| | | | |

| Должность судьи | Фамилия, инициалы | Город | Судейская категория |
|---|---|---|---|
| Главный судья | | | |
| Главный секретарь | | | |
| Ст. Судья | | | |

| Утверждение документа Федерацией, Союзом, Ассоциацией, отделом Минспорта России | | |
|---|---|---|
| Решение Федерации, Союза, Ассоциации | Протокол № | |
| Президент Федерации (союза, Ассоциации) | __________ (____________) | Дата |
| Ответственный секретарь ФРМС | __________ (____________) | Дата |
| Ответственный исполнитель | __________ (____________) | Дата |
| Отдел присвоения спортивных званий | Подпись __________ | Дата __________ |
| Подпись ответственного лица о причинах отказа и отметка о нарушениях | | Дата __________<br>Подпись __________ |

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

| **ПРЕДСТАВЛЕНИЕ** | **КМС, 1 разряд**<br>Необходимо выбрать | | | Фото<br>2 шт.<br>(3×4 см)<br>в блоке |
|---|---|---|---|---|
| Вид спорта | | | | |
| Фамилия | | Имя | | |
| Отчество | | Дата рождения | число / месяц / год | |
| Республика, край, область, округ | | Город (село, поселок) | | |
| ВДФСО, ведомство | | Спортивная школа | ДЮСШ, СДЮШОР, ШВСМ<br>ненужное зачеркнуть | |
| Образование | | Образование физкультурное | | |
| Место учебы (работы), должность | | | | |
| Домашний адрес | | | | |

| Действующий разряд | Дата присвоения или подтверждения | Ф.И.О. тренеров подготовивших спортсмена | Тренерская категория |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| Региональная спортивная федерация | Структурное подразделение для военно-прикладных и служебно-прикладных видов спорта (республ., края, области, округа) |
|---|---|
| М.П.<br>**Руководитель**<br>(подпись) | М.П.<br>**Руководитель**<br>____________<br>(подпись) |
| Дата | Дата |

**ОСНОВНЫЕ ПОКАЗАТЕЛИ (нормативы)**

| Дата выполнен. ч-ло, м-ц, год | Наименование соревнований (дисциплины, вес, количество участников) | Ранг, категория соревнов. | Показ. Результат |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| Должность судьи | Фамилия, инициалы | Город | Судейская категория |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Памятка:

**В соответствии с ЕВСК (новое ЕВСК действует с 02.04.2017):**

1. Срок подачи документов в течении 4 месяцев с выполнения установленных норм.
2. Судейская бригада для выполнения разряда КМС – не менее судей: ВК-1чел, 1К -2чел.
3. Судейская бригада для выполнения 1 разряда – не менее судей: 1К-2 чел, 2К-1чел
4. Соответствие количества участников, команд, поединков и т.д.
5. Соблюдение возрастных требований с учетом вида спорта.
6. Срок действия спортивного разряда: КМС-3 года, 1 разряд- 2 года.
7. Квалификационные требования по видам спорта размещены на сайте Минспорта РФ: http://minsport.gov.ru/sport/high-sport/edinaya-vserossiyska/

*Приказы о выполнении спортивного разряда публикуются на сайте МДМС РТ (в разделе Физкультура и Спорт- Наградные приказы)

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

Спорт дәрәҗәсен һәм спорт разрядыннан мәхрүм итү һәм яңадан торгызу турында гариза

1.______________________________________________

(фамилия, исеме, атасының исеме (булган вакытта),

2.______________________________________________

спортчының туу датасы

3.______________________________________________

(Оешманың спорт разряды, дәрәҗәсе бирү турында документының датасы һәм номеры)

4.______________________________________________

________________________________________________

(спорт разрядыннан, дәрәҗәсеннән, квалификация категориясеннән мәхрүм итү һәм яңадан торгызу сәбәпләрен раслый торган белешмәләр (мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен сәбәпләрне раслый торган документларны теркәп).

________________________________________________

Үтенеч юллаучы оешманың вәкаләтле затының вазыйфасы атамасы, имзасы, фамилиясе һәм инициаллары

-------------------------------

<*> Үтенеч җибәрүче оешма (региональ спорт федерациясе) бланкында рәсмиләштерелә.

Гаризаны теркәү турында билге № ________________________

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

Спорт хөкемдары категориясеннән
мәхрүм итү һәм яңадан торгызу турында гариза

1.______________________________________________

(фамилия, исеме, атасының исеме (булган вакытта),

2.______________________________________________

спортчының туу датасы

3.______________________________________________

(Оешманың спорт разряды, дәрәҗәсе бирү турында документының датасы һәм номеры)

4.______________________________________________

________________________________________________

(спорт хөкемдары квалификация категориясеннән мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен сәбәпләрне раслаучы белешмәләр (мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен сәбәпләрне раслаучы документларны теркәп).

________________________________________________

Үтенеч юллаучы оешманың вәкаләтле затының вазыйфасы атамасы, имзасы, фамилиясе һәм инициаллары

--------------------------------

<*> Үтенеч җибәрүче оешма (региональ спорт федерациясе) бланкында рәсмиләштерелә.

Гаризаны теркәү турында билге № ______________________________

Спорт разрядларын, спорт
хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу  һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

______________________
(оешма атамасы, оешма җитәкчесенең яисә оешма вәкиленең
Ф.И.Аи)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Документ (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

_____________________________________________________________да
(бирелгән документ)
күрсәтелгән:
_____________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:
_____________________________________________________________
_____________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүегезне үтенәм.

Түбәндәге документларны тәкъдим итәм:

1.
2.

Документның әзер булуы турында миңа хәбәр итүегезне сорыйм

_____________________________________________________________
(хәбәр итү юлы)

_______________ _______________ (_______________________)
(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу һәм
Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 10 нчы кушымта
(белешмә буларак)

Спорт разрядлары, «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категорияләре бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы дәүләт хезмәте күрсәтүләре һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәре һәм «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясе бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдим итүләр юллау өчен җаваплы вазыйфаи затлар реквизитлары

| Вазыйфасы, ФИАи | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 222-81-02 | mdms@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 222 -81-09 | Halil.Shayhutdinov@tatar.ru |
| Спорт төрләрен үстерү бүлегенең әйдәп davruchy киңәшчесе | 222-81-19 | Liriya.Gilyazova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппараты**

| Вазыйфасы, ФИАи | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча бүлек | 264-77-01 | enter@kabmin.tatarstan.ru |

Спорт разрядларын, спорт хөкемдарының
«Беренче категорияле спорт хөкемдары»
квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү,
яңадан торгызу  һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына
спорт исемнәрен яисә «Бөтенроссия категорияле
спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү,
мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 11 нче кушымта

## Гамәлләр эзлеклегенең блок-схемасы

